Гыйлемханов, Риман. Үзең булып кал, яме! / Р. Гыйлемханов // Ватаным Татарстан. – 2022. – №148 (8 октябрь). – Б. 5.

# ҮЗЕҢ БУЛЫП КАЛ, ЯМЕ!

**Түгәрәк**

**Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла беркөине: «Абзый, Чаллыга барып кайтмыйбызмы? Рафис Сәлимҗанов җитмешен тутыра. Сез бер тирәдә укыдыгыз да бугаи», - диде. «Мин аның иҗатын юньләп белмим дә бит, җитмәсә, тешләрем дә юк, ничек кенә сөйләрмен соң?» - дигән булам. Ркаил, көтмәгәндә: «Тешең булмагач, ашамый утырырсыц», - диде. Шаяртырга аңа куш инде, күңелләрендә юмор хисе булмаганнарны язучыга да санамый Ркаил**.

Кыяфәте бер карашка шактый җитди тоелган Рафисны да юморист, Рабит Батулла әйтмешли, «йомры телле» язучы дияргә була. Батулла «юмор» дигән сүзне дә татарның «йомры» дигән сүзеннән алынган дип саный. Язганнарым, бәлки, шаярту кебек тә тоелыр, әмма һәр шаярту, йомры сүз астында тирән мәгънә ята бит.

Рафис Сәлимҗановның «Великий язык тюрков» дигән саллы китабы - шуңа бер мисал, дәлил. Бу - әдипнең икенче генә китабы. Әмма, Рафис уены-чыны белән дигәндәй, бик эчкәре кереп киткән, төрки телләрнең, шул исәптән татар теленең нинди бөек, бай тел булуын, башка телләрне баетуга нинди йогынты ясавын мисаллар ки- терә-китерә раслый алган.

Чаллыда Муса Җәлил исемендәге китапханәдә узган очрашуда Казан кунакларыннан өч халык шагыйре: Ркаил Зәйдулла, Марсель Гали, Газинур Морат, Рафисның якташы Алмаз Хәмзин һәм «ашамый утыручы» абзагыз катнашты.

Бераз гына лирик чигенеш ясыйк әле. Университетта бер чордарак укысак та, Рафисны күргәнем булмады. Дөрес, аны . матбугатта чыгып килгән хикәяләре аша белә идем. Хәтта шаян хикәяләре тупланган «Елан мөгезе» дигән китабындагы ике хикәясен концертларда сөйләп тә йөрдем. «Грипп» һәм «Дүртенче Әхмәт» дип атала иде алар. Ул заманда кеше көлдерәм дип, репертуарга билдән түбән мәзәкләр алу юк иде. Яраткан авторларым Гамил Авзал, Фаил Шәфигуллин һәм Рафис Сәлимҗанов булды. Ә язмыш безне узган ел гына очраштырды. Яшел Үзәннең «Волга» шифаханәсендә бергә ял итәргә насыйп булды. «Насыйп булды» дип махсус язам, чөнки моны очраклылык дип санамыйм. Рафис белән яшәешкә, җәмгыять тормышына, илдә-җирдә булган вакыйгаларга карата.

Инде ничә еллар Язучылар берлеге әгъзасы булып та, нибары ике генә китабы дөнья күрү, бер уйлаганда, Рафисны бик үк бизәми кебек. Әмма, Ркаил Зәйдулла әйтмешли, күпме шигырьләр язган, күпме шагыйрьләребезгә китаплар чыгарырга ярдәм иткән Дәрдемәнднең нибары бер китабы чыккан. Хикмәт санда түгел. Кайбер язучылар, фәлән хәтле китабым чыкты, дип горурланырга ярата.

Искә килеп төште. Алмаз Хәмзин дә «Озак яшисең килсә» дигән китап чыгарган иде. Бик бәләкәй иде ул. Каләмдәшләре аңа: «Китабыңны нигә зуррак итеп чыгармадың?» - дип әйткәләгәннәр. Ә Алмаз: «Кибет киштәләрендә башкаларның китапларына урын күбрәк калсын өчен», - дип, тегеләрнең авызларын яба торган.

Рафис та, китап язам, дип дөнья шаулатып йөрмәде. Дөресен әйткәндә, кайберәүләр татарда андый язучы барын да белеп бетермиләр, ишеткән бар бугай, дип сөйләнәләр. Инде менә белегез. Тыйнак кына Рафисыбыз, Марсель Гали әйтмешли: «Кеше күзенә бик чалынмыйча, тыныч кына йөреп, менә дигән китап язу өчен түл җыеп яткан иткән бит!»

Марсельнең берәр кеше турында егылып китеп мактау сүзләре әйткәнен ишеткәнем юк. Ә менә Рафис Сәлимҗанов иҗатына югары бәя бирүе «үз өендә хуҗаны яманларга ярамый», дию белән һич тә бәйле түгел.

Рафисның «Великий язык тюрков» дигән китабы тарих төпкелләрендә казынып язылган. Газинур Морат Рафисны, тел гыйлеменә археология фәнен дә өстәүче, дип бәяләде. Әгәр «археолог» та булмаса, Рафис дөнья халыклары телләре турында бу хәтле мәгълүмат туплый алмаган булыр иде. Аның китабы - гыйльми хезмәт. Рафис аны 2010 елда ук язган булган. Нигә кеше күзеннән яшереп яткандыр, шайтан белсен. Үзе әйтүенчә, баштарак күңелендә икеле-микеле уйлар туган булган. Чөнки язганнары көтелмәгән фикерләргә, татар теленең бөеклеге турында кеше ышанмаслык дәлилләргә бай. Бәлки, үзен милли шовинизмда гаепләүчеләр дә табылыр юморга төреп язган. «Чынлап әйтәме бу Рафис, әллә шаяртамы? - дип баш катырсыннар әле дип - егылып дип шикләнгәндер. Шуңа күрә. китабын җиңелчә уйлагандыр.Марсельнең берәр кеше турында

Миңа анын китапны рус телендә язуы да сәер тоелдь:. Югары белемле татар филологы нигә әле үз теленнән ваз кичкән? Бу хакта үзеннән дә сорадым. «Русчаны күбрәк кеше укыр», - дип уйладым диде дә моңсуланьш китте әдибебез. Гомер буе миллә кайгысы белән яшәгән егетне аклап була иде.

Әле Татарстанга мөстәкыйльлек даулап йөргән елларда ук Чатлы тавышы көчлерәк ишетелә иде. Ул чакта төрле листовкалар, исли азатлык таләп итү белән бәйле саггха документларны бастырып чыгару бик четерекле эш иде. Милләтпәрвәрләребезгә аяк чалырга теләүчеләр әледән-әле табыла торды. Кискен хәрәкәтләр ясарга хакимият тә шикләнде. Һәм әлеге документлар Рафис Сашмжановның шәхси типографиясендә басылып, «КамАЗ» машиналарына төялеп, Казанга, милләттәшләребез яшәгән төрле төбәкләргә озатылды.

Рафис мәйданнарга чыгып күкрәк сукмады, ачлык игълан итмәде, шул ук вакытта үз агымнары белән көрәшүдән дә туктамады. Ул - бүген дә көрәшче. Үз-үзе, дуслары, хәтта гаиләсе белән көрәшә. Мин аның гаиләдә русча сүз кыстырып сөйләшкән кешегә штраф сатуына гаҗәпләндем. Бер сүз саен 10 тәңкә түләтә икән. «Ул хәтле үк ки-рәкмәс иде, чын диктатор икәнсен», - дип сөйләндем. Ә ул елмаеп кына куйды:. Балаларда туган телгә мәхәббәтне әнә шулай уен белән дә тәрбияләп була. Гаиләдә моны җәза бирү дип түгел, ә закон бозган өчен җавап бирү дип кабул итәләр»,- диде.

Шунысы кызык: Ркаил Зәйдулла гаиләсендә дә шундый ук «язылмаган закон яши икән. Тик штраф 10 түгел, ә 1 тәнкә генә, ди. Ркаил шуларны әйтте дә. бер кызык сөйләп куйды. Бер көнне Ркаилнең кечкенә кызы әтисе каршына килеп баскан да: «Менә син штраф түләтәсең, ә «штраф» дигән сүз татарча ничек була соң?» - дип сораган. Ни дип җавап бирергә дә аптыраган Ркаил. Без дә аптыраушта калдык. Тиз генә Интернетка кереп караган идем, «штраф» немец сүзе икән, хокук бозган өчен законлашты- рылган җәза бирү дигәнне аңлата. «Значит, - мәйтәм, - «штраф» рус сүзе булмагач, аның өчен штраф сала алмыйсың». Кайсыбыздыр: «Ә синең «значит»ың өчен салырга була», - дип көлеп куйды. Күңелдә исә телебезнең киләчәге турында борчулы уйлар иде. Рафис, бәлки, «штраф» дигән сүзнең татардан килеп чыккан икәнен дә дәлилләр әле. Бәлки, телебезне саклау һәм үстерүгә кагы- лышлы яңа законнар, карарлар да кабул ителер. Инде дустыбызның язучылык һөнәренә, китаплар чыга- руга килгәндә, әдипнең тагын әллә ничә китап



нәшер итәрлек кульъязмалары җыелган икән. Ә «Великий язык тюрков» китабын Кавказ республи- каларының кайберләрендә кулдан-кулга йөртеп укыйлар дип ишеттем. Ркаил Зәйдулла аны төрек һәм тагын берничә телгә тәрҗемә итәр¬гә кирәк дип саный.

Гөнаһына керәсем килми, бу китапны үзем ту- лысынча укып чыкмадым әле. Беренчедән, ул са- туда юк икән инде, әмма электрон версиясен укырга була.

Саубуллашыр алдыннан Рафиска: «Бер-ике китап белән генә калма, барыбер Дәрдемәнд була алмас- сың, безгә Рафислар да кирәк, үзең булып кал, яме»,-дидем.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ